**«Киләчәк бүген дә аналар кулында»**

Балтач гимназиясендә 2021 – Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы кысаларында **«Киләчәк бүген дә аналар кулында»** дигән җылы очрашу – чара узды. Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Рәйсә Әхмәтова җыенны мәгънәле, итагатьле, гади итеп алып барды. Таш булып каткан күңелләр дә эрерлек иде хәтта.

Биредә сыйныф җитәкчеләре, эти - әниләр, килгән кунаклар һәм район мәгариф идарәсе җитәкчесе Алия Шагаева катнашында бала тәрбияләү мәсьәләсендә фикер алыштылар.














